Илһам Фаил улы Фәттахов,

филология фәннәре кандидаты,

Казан федераль университеты доценты

Мәдрәсәдә татар теле укытуның үзенчәлекләре

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин. Вәлгаакыйбәтү лил-мүттәкыйн. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһии вә сахбиһии әҗмәгыйн!

Әссәләәмүгаләйкүм вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләр, газиз милләттәшләр!!!

“Дингә һәм халыкка хезмәт итү юлында” 20 еллык мөбарәк юбилеен зурлап билгеләп үтүче “Ислам динен кабул итүгә 1000 ел” исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең хөрмәтле ректорын, мөгаллимнәрен, шәкертләрен һәм чакыруны кабул итеп килгән кадерле кунакларны шушы олы бәйрәм белән ихлас күңелдән кайнар котлыйм! Сезнең барыгызга да нык сәләмәтлек, гамәл-гыйбадәттә иман ныклыгы, хезмәтегездә зур уңыш, тормышыгызда бәрәкәт Аллаһ насыйп итсен дип телим.

Яраткан мәдрәсәбездә мин 2000-2004-нче уку елларында татар телен укыттым. *Туган телебезгә мәхәббәтне* Габдулла Тукайның “Шүрәле” поэмасын, “Туган тел”, “Пар ат”, Сәгыйт Рәмиевнең “Уян, татар!”, “Таң вакыты”, Дәрдмәнднең (Закир Рәмиев) “Урысча күп сүзең, азы татарча”, “Рәсем”, “Җәй үтте”, “Видагъ” (“Аерылышу”), “Кораб” шигырьләрен ятлатып тәрбияләсәм, аның грамматикасын филология фәннәре докторлары, академиклар Диләрә Гариф кызы Тумашева, Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев, профессорлар Фәрит Йосыф улы һәм Рүзәл Габдуллаҗан улы Йосыповлар, тел галимәләре Флёра Садрый кызы Сафиуллина, Клара Зыя кызы Зиннәтуллина һәм Казанның 10-нчы интернат-мәктәбендә (хәзерге 2-нче татар гимназиясе) дистә еллар ана телен нәтиҗәле укыткан Тихния Миргалим кызы Гайфуллина дәреслекләре буенча өйрәттем. Хәтерләрен яхшыртыр өчен татарча дога текстлары ятлаттыра идем.

Татарстан Мөселманнары Диния Нәзарәте уку-укыту бүлегенең элекке мөдире Рифкать хаҗи, Татарстан Министрлар Кабинетының дин эшләре идарәсеннән җаваплы вәкил Венера ханым катнашында татар теленнән ачык дәрес бирдем, алар үз чиратында уңай бәя бирделәр.

Мәдрәсә шәкертләренең контингенты көндезге бүлектә даими рәвештә 60-лап иде. Өстәвенә читтән торып уку бүлеге һәм кичке мәдрәсә бар. Әгәр безнең шәкертләрнең географиясен карасак, бөтен җиһанга таралган татарның балалары Казаннан, Татарстанның, нигездә, Балтач, Арча, Әтнә, Кукмара, Саба, Теләче, Мамадыш, Питрәч, Яшел Үзән, Апас, Кайбыч, Буа, Актаныш районнарыннан, Россиянең Пермь, Свердлов, Оренбург төбәкләреннән, Төньяк Осетиядән, хәтта Казахстаннан дини белем алырга дип рухи мәркәзебезгә киләләр. Башкалабыз аларның һәммәсен дә, халкымның киң күңеле кебек, үз кочагына сыендыра. (1917 елга кадәр дә шулай булган бит, Казанның данлыклы "Мөхәммәдия", "Күл буе" мәдрәсәләренә төрле җирләрдән килеп укыганнар.) Шуңа күрә шәкертләр татар телен белү ягыннан өч төркемгә бүленә иде:

1. "Саф" татар авыл мәктәбен тәмамлаучылар, ягъни ана телен камил дәрәҗәдә белүчеләр;

2. Милли гимназия яки рус-татар гомумбелем мәктәбеннән килүчеләр (болары инде туган телгә урыс сүзләре кыстырып сөйләшергә ярата яки татарчадан автоматик рәвештә рус теленә күчә);

3. Рус мәктәпләрендә укыган, ягъни урыслашкан, нәтиҗәдә татар телен оныткан яшүсмерләр. Мондыйлар мәдрәсәгә килүчеләр арасында, Аллаһка шөкер, берән-сәрән генә булды.

Бәхеткә, менә шундый "чуар" балаларны ана теленә өйрәтергә Ходай насыйп итте миңа. Үзебезчә, нәкъ менә татарча, чат итеп сөйләшүче Арча-Балтач егетләрен рәхәтләнеп укытырга яки татарлашкан "урыс" малае Валера (мөселманча исеме – Габделвәли, Екатеринбург тирәсеннән) кебекләрдән алты килешнең сорау-кушымчаларын кат-кат кабатлатып, сүзләрне өч заман формасында төрләндереп, үзләрен шактый гына газапларга туры килде. Ләкин мин аларның чын мәгънәсендә маңгай тире түгеп ирешкән уңышларына сөенә идем. Бүген дә үземнең тырыш, акыллы шәкертләрем белән бик горурланам. Хәзер аларның күбесен мәчеттә имам вазыйфасында күрәм, кайберләрен Россия Ислам университетында яисә Казан федераль университетында очратырга мөмкин. Араларында Мисырның атаклы Әл-Әзһәр дарелфөнүнендә (Каһирә), Тунисның Әз-Зәйтүн университетында озак вакыт укып, дини гыйлем туплап кайтучылар да юк түгел.

Шәкерт күңелендә *тарихи хәтерне уяту, аңа милли үзаңны сеңдерү* максатында тарихи әсәрләр укытып эчтәлеген сөйләттерә идем, мәсәлән: Нурихан Фәттахның "Итил суы ака торур" ("Идел суы ага торыр"), Мөсәгыйт Хәбибуллинның "Кубрат хан", Җәмит Рәхимовның "Батырша" романнары, Вахит Имамовның "Сәет Батыр" тарихи повесте.

Шәкертләрнең эрудициясен арттыру өчен, аларда дөньяга карата киң фикерләү булдыру өчен халкыбызның күренекле галимнәрен мәдрәсәгә чакырып, Ильяс хәзрәт белән берлектә очрашулар үткәрдек. Әйтик, татар фәлсәфәчесе Яхъя ага Абдуллин, филология фәннәре докторы Марсель абый Әхмәтҗанов, тарихчы Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев, сәясәт фәннәре докторы, Ислам дине белгече Рәфыйк Мөхәммәтша улы Мөхәммәтшин катнашында узган җылы күрешүләр яшь буын йөрәгендә якты эз калдырдылар. Кайбер сәләтле, кызыксынучан шәкертләр күпне белергә теләп кунакларга байтак кына сораулар да яудыра иде. Ахырдан бергәләшеп истәлеккә фотога төшә идек.

Мин шәкертләрне мәдәният программасы кысасында берничә тапкыр Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына иң милли язучыбыз Гаяз Исхакыйның “Зөләйха” драмасы буенча куелган спектакльне карарга алып бардым. Шулай ук Татарстанның Милли музее залларында булдык, төрле-төрле күргәзмәләр карап йөрдек. Димәк, егетләрнең *рухи дөньясы* тагын да матурланган, баеган, ә *күңел күзе* яхшырак күрә башлаган дип уйлыйм.

Әле без дүрт ел рәттән, алтын көз килгәч яки ямьле яз җиткәч, Яңа Татар бистәсе зиратына бара торган идек. Менә әбиләр чуагы (җәе) башланып, һавада тоҗым-тоҗым булып үрмәкүч пәрәвезләре очкан көннәрнең берсендә, төгәлрәк әйтсәк, шимбә көнне алты дәрес укыганнан соң изге җиргә юл тотабыз. Көн җылы, агачлар сап-сары, әйтерсең лә, алтын сыман күлмәк кигәннәр. Җиргә талгын гына сары яфрак коела. Пәрәвез җепләре авыз-борын тирәсенә килеп ябыша. Көзге Кояшның саран гына, әмма җылы нурларына коенып, Вахитов тимер юл станциясе буйлап атлыйбыз.

Бу зиратта кемнәр генә күмелмәгән? Милләтебезнең асыл уллары, уңган-булган кызлары: күренекле Шиһабеддин Мәрҗәни хәзрәтләре, Казан мөселманнары кулыннан төшми укылган атаклы “Гыйбадәте Исламия” (“Ислам гыйбадәте”) китабы авторы Әхмәдһади Максуди да монда күмелгән, милли шигъриятебезнең даһие Тукай, аның иң якын дуслары Хөсәен Ямәшев, Фатыйх Әмирхан, бөек артист Габдулла Кариев, билгеле шагыйрьләребез С.Рәмиев, Х.Туфан, С.Хәким каберләре, язучыларыбыз Сталин премиясе лауреаты Гомәр Бәширов, фронтовик Нәби Дәүли, талантлы композитор Сара Садыйкова да монда... һ.б., һ.б.

Изге урынга аяк баскач, шәкертләрдән берсе, гадәттә, иң оста укучысы моңлы, аһәңле тавышы белән Коръән-Кәримнән кыска сүрәләр яңгырата. Аннары Тукай кабере янында туктап, зираттагы барлык әрвахларга – мәрхүм-мәрхүмәләрнең рухлары тыныч йокласын, урыннарын Аллаһ җәннәттән

кылсын дип дога кылабыз. Безнең күз төпләре дымлана, күңелләребез тәмам тула...

Инде сөйләшә-сөйләшә кире кайтабыз.

- Динебез чардуган, каберташларын куймаска куша, - дип сүз башлый Рамил шәкерт. – Болар исраф бит!

- Бу – бидгать, әстәгъфируллаһ, - ди Габделвәли.

- Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.с.) әйткән хәдисе бар: “35 елдан соң кабер өстенә иген чәчегез”, - дип сүзгә кушыла Ренат шәкерт. – Шуңа күрә гарәп илләрендә, мәсәлән, Согуд Гарәбстанында бездәге кебек зиратлар юк.

- Без бит гарәп дәүләтендә яшәмибез лабаса! – дим мин. – Кайда яшәгәнегезне онытмагыз, егетләр! Безнең үз традицияләребез, милли һәм дини гореф-гадәтләрне хөрмәт итик.

- “Чын” Исламга каршы киләсез, Илһам хәзрәт, - дип тәнкыйтьли мине, әңгәмәгә кушылып киткән Рәмис шәкерт. – Сез менә мондагы “яңа татарлар” аллеясенә ничек карыйсыз? Шундый зур кара мәрмәр ташлар куюны хуплыйсызмы?

- Мин татарлардагы “традицион Ислам” буенча яшәргә кирәк дип чакырам. Артык кыйммәтле ташлар куюны һич якламыйм, мәрхүмне генә баса ул.

- Әнә мөселман динендәге ниндидер чегән бароны басып тора, - ди Радик, шаккатып. – Мондый сын куйганчы, нигә ятим балалар йортларына, мескеннәргә ярдәм итмәскә?

Шул рәвешле сөйләшеп, мәдрәсәгә кайтып җиткәнебезне сизми дә калабыз. Тәһарәтләнеп, икенде намазын укыгач, кемдер авылга китә, Казан егетләре исә өйләренә җыена, ә калган шәкертләр татар, гарәп телләреннән һәм башка фәннәрдән өй эше эшләргә утыра...